**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

2013 ел, 3 июнь Казан № 01-02/37

**Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрын оештыру һәм алып бару тәртибе турында аңлатмаларны раслау хакында» 2009 елның 31 мартындагы 01-02/70 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә боерам:

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2009 елның 31 мартындагы 01-02/70 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару тәртибе турында аңлатмаларга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзгәрешләр (өстәмәләр) кертә, озайта, туктатып тора, юкка чыгара, үз көчен югалткан дип таный һәм (яисә) элек кабул ителгән (бастырып чыгарылган) муниципаль норматив хокукый актлар гамәлдә түгел дип таный торган актлар»;

1.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өстәмә белешмәләр (муниципаль норматив хокукый актның яисә аның аерым нигезләмәләренең законнарга, муниципаль берәмлек уставына туры килүе (туры килмәве) турында Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының эксперт бәяләмәсеннән тыш) җирле үзидарә органнарына, җирле үзидарәнең вазыйфаи затларына керү дәрәҗәсе буенча Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелә.

Өстәмә мәгълүматларга түбәндәгеләр керә:

муниципаль норматив хокукый актларга карата кабул ителгән прокурор реакциясе актлары (судка тәкъдимнәр, протестлар һәм гаризалар);

муниципаль норматив хокукый актларга дәгъва белдерү турындагы эшләр буенча суд актлары;

муниципаль норматив хокукый актларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүен тикшерү турындагы эшләр буенча Татарстан Республикасы Конституция суды карарлары һәм билгеләмәләре;

монополиягә каршы федераль хезмәтнең федераль законнарга каршы килә торган актларны юкка чыгару яисә үзгәртү турында җирле үзидарә органнарына адресланган күрсәтмәләре;

җирле үзидарә органнарының федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны җайга сала торган өлешендә муниципаль хокукый актларның гамәлен юкка чыгару яисә туктатып тору турында дәүләт хакимияте органнары актлары;

прокуратура органнарыннан кергән таләпләр, хатлар, башка мәгълүмат, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, башка дәүләт органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан кергән хатлар һәм башка мәгълүмат.»;

1.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль норматив хокукый актлар машина укый торган күчергечтә (дискта, дискетта, флешкада) яки элемтә каналлары аша, электрон почта аша Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы бүлеген алып баручы белгечләр адресларына җибәрелә. Белгечләрнең электрон адреслары Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы сайтында http://minjust.tatar.ru. бирелгән»;

түбәндәге эчтәлектәге 1.10 пунктны өстәргә:

«ТР Юстиция министрлыгы запросы буенча, муниципаль норматив хокукый актның электрон төренең актның кәгазьдәге эчтәлегенә туры килүен билгеләү максатларында, соратып алына торган акт тиешле җирле үзидарә органы мөһере һәм вәкаләтле вазыйфаи зат имзасы белән таныкланган рәсми күчермә рәвешендә тапшырыла.»;

2.3, 2.4 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлектәге 3 бүлекне өстәргә:

«3. Муниципаль норматив хокукый актларга юридик экспертиза үткәрү

3.1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы муниципаль регистрны оештыру һәм алып бару буенча:

муниципаль норматив хокукый актка Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук муниципаль берәмлек уставына туры килү-килмәүгә юридик экспертиза үткәрә. Юридик экспертиза муниципаль норматив хокукый акт Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына кергән көннән алып кырык биш көннән дә соңга калмыйча үткәрелә. Кирәк булганда, әлеге срок озайтылырга мөмкин, әмма унбиш көннән дә артык түгел;

муниципаль норматив хокукый актның яисә аның аерым нигезләмәләренең законнарга, муниципаль берәмлек уставына туры килүе (туры килмәве) турында эксперт бәяләмәсе төзи һәм мондый бәяләмәне муниципаль регистрга кертә.

3.2. Муниципаль норматив хокукый актта Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль берәмлек уставына каршы килә торган нигезләмәләр ачыкланганда, эксперт бәяләмәсе мондый актны кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органына (җирле үзидарәнең вазыйфаи затына), шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һәм прокуратура органнарына җибәрелә.»;

3 бүлекне пунктларның номерациясе үзгәреше белән 4 бүлек дип санарга һәм түбәндәге эчтәлектәге 4.3 пунктны өстәргә:

«4.3. Регистрдагы мәгълүматлар электрон формада бирелә:

Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге дәүләт хезмәтләренең бердәм сайты (дәүләт хезмәтләре порталы) яки муниципаль норматив хокукый актларның федераль регистры порталы аша;

электрон почта ярдәмендә.».

2. Әлеге боерыкны теркәргә һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын дәүләт реестрына кертергә.

3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы юстиция министрының беренче урынбасары С.Н.Столяровка йөкләргә.

Министр М.М.Корманов